

# Хокук кешегә хезмәт итә.


# Дәреснең планы

1. Нәрсә ул хокук?
2. Хокук чыганаклары.
3. Юридик җаваплылык.
4. Өй эше.

# 1. Нәрсә ул хокук?

***Хокук – барлык кешеләр өчен дә мәҗбүри булган юридик нормалар, (кагыйдәләр) системасы.***

- Хокук
- Мәҗбүр итә (автобуста утырып барган өчен түләргә кирәк, кагыйдәне бозган өчен штраф түләтелә)
- Нәрсә дә булса эшләү мөмкинлеге бирә (Кибеттән нәрсәдә сатып алырга мөмкин. Берәү дә мәҗбүр итми. Бу кешенең хокукы)
- Кешеләрне нәрсәдәндер тыярга мөмкин (мәсәлән, үтерүләр, урлаулардан)



# 2. Хокук чыганаклары.

Хокук төрле чыганакларда, бигрәк тә законнарда аңлатыла. Закон текстларын юристлар яза. Законның атамасы, номеры була, һәм ул юридик кагыйдәләр язылган статьялардан тора.







<u>*Закон*</u> – әһәмиятле юридик документ. Анда язган кагыйдәләрне үтәү мәҗбүри.

Законарның төрләре:

- *Конституция (илнең төп законы, ул җәмгыятьнең һәм дәүләтнең төзелешен, хакимият органнарын оештыру тәртибен, сайлау системасын, гражданнарның төп хокукларын һәм бурычларын билгели);*
- *Кодекслар (мисал өчен: Җинаять, Гражданар, Гаилә, Хезмәт, Салым, кодекслары һ.б.);*
- *Указлар, уставлар* (Мисал өчен Президентның 2015 елны - Әдәбият елы дип игълан итү. Мәктәптә төп закон – мәктәп Уставы. Анда укучыларның хокук һәм бурычлары күрсәтелә)



# 3. Юридик җәваплылык.

***Юридик җаваплылык –*** **кешеләрнең хокукый нормаларны бозган өчен җәвап бирү бурычы.**

**Җинаять эшләре – кеше кылган иң куркыныч гамәлләр. Алар җинаять кодексында күрсәтелгән.**

Безнең илдә җинаять җәваплылыгы 16 яшьтән башлана, тик аеруча зур җинаятьләр өчен 14 яшьтән дә җавапка тарту каралган (үтерү, талау, терорчылык турында ялган хабәр һ.б.)







# Өй эше:

§17 укып килергә.

3 нче сорау телдән,
4 нчесе язмача.

